КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1103

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2016 ел, 28 июль, 519 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2016 ел, 28 июль, 519 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 26 июнь, 437 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлегенә, түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пунктны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«$6^1$. Коммуналь ресурслардан һәм коммуналь хезмәтләрдән файдалануны исәпкә алуның автоматлаштырылган мәгълүмат-үлчәү системаларын урнаштыру.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин